Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр
башкарма комитеты
422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района Республики
Татарстан
исполнительный комитет
города Арск
422000, РТ, г.Арск, площадь Советская, 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**« 18 » декабрь 2025 ел** **№ 224**

**Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, “Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставы, “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау турында” 2021 елның 25 октябрендәге 51 номерлы Арча шәһәре Советы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” җыеннарында кабул ителгән 2025 елның 14 ноябрендәге 1 номерлы, 2025 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы, 2025 елның 19 ноябрендәге 3 номерлы, 2025 елның 20 ноябрендәге 4 номерлы, 2025 елның 21 ноябрендәге 5 номерлыкарарларын гамәлгә ашыру максатларында Арча шәһәре Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Арча шәһәре башкарма комитетының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында” 2022 елның 23 декабрендәге 202 номерлы карарын (2023 елның 6 февралендәге 19нчы номерлы үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында: Иске Айван ав., Яшьләр ур., 1а йорт, Күпербаш ав.,

Мичурин ур., 10 йорт, Зур Бирәзә ав., Г. Тукай ур., 25 йорт, урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җитәкче урынбасары Г.Г.Ибәтуллинага йөкләргә.

Арча шәһәре
башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф.Касыймов

Арча шәһәре башкарма
комитеты карарына
“18” декабрь 2025 ел, № 224
1 кушымта

**Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә нинди мөнәсәбәттә булуларына карамастан, 2026 елның 1 мартына кадәр түлиләр.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) махсус хәрби операциядә катнашучылар (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле хезмәткәрләр) һәм аларның гаилә әгъзалары (бергә яшәүче әти-әниләре, ирләре яки хатыннары, балигъ булмаган балалары).

4. Гражданнарның аерым категорияләре өчен түләү күләме 100 сум тәшкил итә:

а) I төркем инвалидлар,

б) 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар,

5. Нигезле сәбәпләр булган очракларда гражданнарга гариза нигезендә түләү кертүне өч айдан да артмаган вакытка кичектерү бирелә. Нигезле сәбәпләр булып санала:

а) гаилә әгъзасының (әти-әнисенең, иренең/хатынының, балаларының) вафат булуы;

б) янгын яисә башка табигый бәла-казалар аркасында зыян килү.

6. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәр итү бланкы (http://pravo.tatarstan.ru/) сайтында бастырып чыгару һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру, шулай ук кул куеп тапшыру яки почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән гражданнарга җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр түләүнең тулы яисә киметелгән күләме, аны түләү вакыты булырга тиеш.

7. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

8. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясарга, почта күчерүләрен башкарырга хокуклы оешмалар

(исәп-хисап оешмалары) аша яисә https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша акча күчерү юлы белән башкарыла.

9. Түләү фактын приход касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслый торган башка документлар раслый.

10. Гражданнарның үзара салым акчалары билгеләнгән вакытта кертелмәгән очракта алар законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Арча шәһәре башкарма
комитеты карарына
“18” декабрь 2025ел, № 224
2 кушымта

“Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджетына
үзара салым акчасы күчерү буенча бер тапкыр түләү турында
**ХӘБӘРНАМӘ**
**№_________**

Түләүченең Ф. И. О. ______________________________________________________

Адрес:____________________________________________________________________

Нигезендә ________________________________________________________________

Сезгә ______________________________________________ вакытка кадәр
______________________________________ чараларын гамәлгә ашыру өчен
_____________ сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә кирәк.
Реквизитлар: ______________________________________________________

Алучы банкның БИК _________________________________________________

Сч. N _____________________________________________________________

Алучының Сч. N ____________________________________________________

ИНН _______________________________________________________________

КПП _______________________________________________________________

КБК __________________ОКАТО ______________________________________

Түләүнең билгеләнеше _______________________________________________

Җитәкче ________________ __________________________________________

М.П. (имза) (имзаны шәрехләү)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

“Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджетына
үзара салым акчасы күчерү буенча бер тапкыр түләү турында
**хәбәрнамә**

_______________ сум күләмендә

Түләүченең Ф.И.О. ______________________________________________________

Адрес: _________________________________________________________________

Алдым "___" _______________ 20__ ел ________________________________________
(Түләүченең имзасы /ФИО)

Искәрмә: хәбәр түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, хәбәрнамәнең өзелә торган өлеше тутырыла һәм һәм Арча шәһәре башкарма комитетында кала.